*Шарафетдинова Нәзлия Вәсим кызы*

*Күҗәкә төп гомуми белем бирү мәктәбе*

6 класста татар теле дәресе

**Тема: Рәвешләр иленә сәяхәт.**

**Максат:** Рәвеш турында алган белемнәрне гомумиләштереп кабатлау; укучыларның белем дәрәҗәсен, логик фикерләү сәләтен тикшерү; туган телнең матурлыгын тоярга өйрәтү.

Җиһазлау: дәреслек, перфокарточкалар, интерактив такта ,карточкалар

Дәрес тибы: дәрес- сәяхәт

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру- ориентлашу.**

Исәнмесез! Хәерле көн укучылар! Бүген бездә татар теле дәресе. Әйдәгез әле, бер-беребезгә карап елмайыйк та, дәресебезнең күңелле, мавыктыргыч үтүен телик.

**II. Дәреснең эш барышы белән таныштыру.**

- Укучылар, без алдагы дәресләрдә сезнең белән рәвеш сүз төркеме турында таныштык. Ә бүген инде рәвеш темасын гомумиләштереп кабатларбыз. Сезнең алган белемнәрегезне, логик фикерләү дәрәҗәгезне тикшереп карарбыз.

Ә инде дәрескә килгәндә, ул гади генә булмаячак. Без аны сәяхәт- дәрес итеп үткәрербез. Аның өчен безгә берничә тукталышка туктап, , андагы биремнәрне үтәргә кирәк булачак..

Шулай итеп, әйдәгез, “Рәвешләр иле” нә сәяхәтебезне башлыйк. Ә безнең сәяхәтебез 4 тукталыштан торачак.

**I тукталыш**

(Экранда 1 нче тукталыш . Андагы бирем укучыларга күрсәтелә.)

| **Р** | **Ә** | **В** | **Е** | **Ш** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

1. Рәвеш нәрсәне белдерә? Ул нинди сорауларга җавап бирә?

2. Рәвешнең нинди төркемчәләре бар?

3.Рәвеш дәрәҗәсе сыйфат дәрәҗәсеннән нәрсә белән аерыла?

4.Рәвеш сүз төркемен билгеләү өчен нинди сүз төркеменнән чыгып сорау куела?

5. Рәвешләр ясалышлары ягыннан ничә төргә бүленәләр?.

- Яхшы укучылар, сез бу биремне җиңел үттегез. Әйдәгез, алга таба китик.Безне анда I I тукталыш көтә.

**I I тукталыш**

Укучылар, безгә бу тукталыштагы биремне үтәү өчен рәвешнең дәрәҗәләрен искә төшерергә кирәк булачак. Аның өчен мин сезгә перфокарточкалар таратам. Сез шуны тутырырга тиеш буласыз.

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Артыклык | | | | | | | | | | |
| Чагыштыру | | | | | | | | | | |

**Бирем**: 1) тизрәк, 2) иң югары,3) якынрак,4) кабат- кабат, 5) әкренрәк, 6) күбрәк, 7) көпә-көндез,8) югарырак, 9) япа-ялгыз, 10) бик күп.

Укучылар, булдырдыгыз ! Сез бу биремне дә җиңеп чыктыгыз. Ә хәзер әйдәгез, бераз ял итеп алыйк.

(Физкультминутка. Укучылар басалар , шигырьне кабатлап, эшлиләр)

Яңгыр ява шып та шып

Тамчы тама тып та тып.

Күк йөзенә карадык,

Битләребез чыланды.

Аяклар юешләнде,

Иңбашларны сикерттек,

Тамчыларны селектек.

Бу яңгырдан качабыз,

Куакларга посабыз.

- Ярый укучылар, юлыбызны дәвам итәбез.Безне алда III тукталыш көтә. Анда без, рәвешләр ясалышы буенча биремнәр эшләрбез.

**III тукталыш**

| Тамыр | Ясалма | Парлы | Кушма | Тезмә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

**Бирем:** сүзләрне таблицага тутырырга.(Укучылар дәфтәрдә эшлиләр)

*Кинәт,берникадәр, бүген,һаман, күз ачып йомганчы,көмештәй, сирәк, яланаяк, ашык-пошык, икеләтә, бер тында,сәгатьләп,уттай. тиз-тиз.*

-Яхшы укучылар, булдырдыгыз. Ә хәзер алга таба , соңгы тукталышка барабыз. IV тукталышта сезгә карточкалар бирелә. Сез андагы җөмләләрдән рәвешләрне табарга тиеш буласыз.

**IV тукталыш**

**1 карточка**

1. Кинәт мәйданның дүрт ягында флаглар күренде.( А. Р.)
2. Биттәге җыерчыклары тирәнрәк төшеп киткәннәр дә бик ешайганнар.
3. Җәен бал җыя, кышын хәл җыя.(табышмак)

**2 карточка**

1. Җыелыш шактый озак дәвам итте.(Ф.Х.)

2. Кошлар күп очракта шәһәр урамнарында һәм бакчаларда өрәңге орлыклары белән туклананалар.

3. Төнлә өйдә, көндез биләмдә.(табышмак)

**3карточка**

1. Очкындай ялтырап, бихисап кар бөртекләре күзне чагылдыра.
2. Төшкә таба күк йөзе ачылып, көн бөтенләү аязланып китте, кояш язча көлеп җибәрде. (Ф.Х.)
3. Язын дөньяга килә, көзен саргаеп үлә. (табышмак)

**4 карточка.**

1. Иртәдән үк көн уйнаклап торды.
2. Бу нәфис кошлар уттай атылып киләләр дә йомшак күкрәкләре белән суны сөзеп- ярып үтәләр.(М.Р.)
3. Югары менә чылбырсыз, түбән төшә баскычсыз, өйләр сала балтасыз. (табышмак)

**5 карточка**

1. Беркөнне өйләдән соң чикләвеккә киттем.( М.Р.)
2. Атасының болай чамадан тыш ягымлыланып китүе аны тынгысызлап узды. ( Г.Б.)
3. Язын ямь бирә, җәен салкын бирә, көзен тәм бирә, кышын тун бирә. ( табышмак)

- Укучылар, сез бу биремдә дә сынатмадыгыз. Рәхмәт сезгә. Шулай итеп сез бүгенге дәрестә “Рәвешләр иле”нә сәяхәт иттегез. Һәрбер тукталышта үз белемегезне сынадыгыз һәм бер дә сынатмадыгыз. Димәк, сез рәвеш турындагы белемнәрне бик яхшы үзләштергәнсез.

**III. Укучыларга билгеләр кую.**

**IV. Өй эше.**

“Минем бүгенге сәяхәтем” дигән темага кечкенә күләмле инша язып килергә.